**МИНИСТЕРСТВО ПРОСВЕЩЕНИЯ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ**

**Министерство образования и науки Республики Татарстан**

**МБУ "Отдел образования" Пестречинского муниципального района РТ**

**МБОУ "Шалинская СОШ имени Сафина Ф.А."**

| РАССМОТРЕНО | СОГЛАСОВАНО | УТВЕРЖДЕНО |
|---|---|---|
| Руководитель ШМО | Зам. директора по УВР | Директор школы |
| ______ Газимова Л.Г. | ______ Биктимерова Л.М. | ______ Мухутдинов А.Б. |
| Протокол № 1 | Протокол № 1 | Приказ № 93 |
| от «28» августа 2025 г. | от «28» августа 2025 г. | от «28» августа 2025 г. |

**РАБОЧАЯ ПРОГРАММА**

**учебного предмета**

**«Литературное чтение на родном (татарском) языке»**

для обучающихся 1-4 классов

**Шали 2025**

## “ӘДӘБИ УКУ” КУРСЫННАН ЭШ ПРОГРАММАСЫ

## АҢЛАТМА ЯЗУЫ

Уку — сөйләм эшчәнлегенең бер төре. Процесс буларак ул барлык телләрдә дә бертөрле: сүзнең график формасын аваз формасына күчерү. Уку — шул ук вакытта танып белү эшчәнлегенең нигезе, аның төп ысулы. Шуңа күрә уку дәресләренең төп бурычы — укучыларда йөгерек, аңлы, сәнгатьле уку күнекмәләре булдыру, текст һәм китап белән эшләү осталыгы тәрбияләү. Уку тизлеге — укучыларның яхшы укуына шарт булып торган иң мөһим фактор. Уку процессында оператив хәтер һәм тотрыклы игътибар үсеш ала, баланың акыл хезмәтенә сәләте исә шушы ике күрсәткечкә бәйле.

Күп укыган бала тиз укый. Шуңа күрә башлангыч сыйныфларда китап укуга һәвәслек тәрбияләү, әдәбиятны сүз сәнгате буларак кабул итәргә өйрәтү мөһим мәсьәлә булып тора. Уку күнекмәләре укуга һәвәслек белән бергә генә үсеш алырга мөмкин.

Моңа бәйле рәвештә II—IV сыйныфларда уку дәресләренә мондый бурычлар өстәлә:

— баланы матур әдәбият әсәрләре дөньясына алып керү һәм сүз сәнгатенең образлылыгын аңларга өйрәтү;

— төрле жанрдагы әдәби әсәрләр белән таныштыру;

— яңа китаплар белән танышуга, элеккеләрен кабат укуга теләк тәрбияләү, китап укудан ләззәт, хозурлык табарга өйрәтү;

— әсәрне уку — аның «серенә» төшенү икәнлеген аңлату, авторның* позициясен, язылганга мөнәсәбәтен ачарга өйрәтү, автор белән аралашу өчен уку;

— әсәрдәге сүзне укучының игътибар үзәгенә кую; аны образлар тудыру алымы, авторның фикерен, уйларын, хисләрен белдерүче чара, автор ачкан могҗиза буларак кабул Итәргә өйрәтү;

— укучыларның әсәрне эмоциональ-эстетик кабул итүенә ирешү; хисләр сферасын әхлакый, рухи матурлык тойгылары белән баету;

— әдәби әсәрләрне укыганда, балаларның акылын, ихтыя.рын, хисләрен һәм рухи ихтыяҗларын үстерү.

Башлангыч сыйныфларда уку һәм югары сыйныфларда әдәбият дәресләре нигездә охшаш, ләкин һәркайсында әдәби әсәр белән таныштыру балаларның яшь үзенчәлекләренә карап оештырылырга тиеш. Түбән сыйныфларда уку дәресе әдәбият дәресе түгел, уку дәресе булып кала — беренче урында уку техникасын үстерү бурычы куела.

Сүз сәнгате белән таныштыру максатыннан, II—IV сыйныфларда әдәбият белеменнән мәгълүматлар бирелә: автор турында белешмә, әдәбиятның төрле жанрлары һәм аларның үзенчәлекләре, әсәрнең темасы, төп фикере, фольклорның кече жанрлары үзенчәлекләре, чагыштыру, эпитет, метафора, җанландыру, рифма, строфа. Ләкин бу терминнарны үзләштерү һәм аларны тексттан таба белү төп максат түгел, алар әсәрне тирәнрәк аңлау өчен кулланылалар.

Әдәби әсәрне тиешенчә кабул итү укучының тормыш тәҗрибәсенә бәйле. Укылганны бала үзенә үлчәп карый, үз фикерен, эш- кыланышларын әсәр героеныкы белән чагыштыра, дөньяны ничек аңлавына карап, образ тудыра, барысын үз аңы, үз тәҗрибәсе аша уздыра. Әсәрне кабул итү, аңлау өчен вакыт таләп ителә. Укучыга әсәрнең сәнгать тирәнлеге беренче тапкыр укыганда ачылмый, кабат укыганда гына яңа ассоциатив бәйләнешләр туа. Кабат укуны оештырганда, биремнәр катлаулана барырга тиеш. Шул очракта гына балалар әдәби әсәрне кабул итү һәм аңлау ягыннан сыйныфтан сыйныфка үсәләр.

Сәнгатьле уку — әсәрне аңлату ысулы. Ул — әсәрне (геройларның халәтен, аларның кичерешләрен, авторның темага, эчтәлеккә мөнәсәбәтен, язылганның матурлыгын) тирәнтен аңлау нәтиҗәсе. Башта сәнгатьле укырга балалар укытучыга охшатып кабатлап өйрәнәләр, соңыннан кайбер әсәрләрне мөстәкыйль рәвештә сәнгатьле укый алалар.

Программаны нәтиҗәле үтәү дә балаларның тормыш тәҗрибәсе туплавына бәйле. Дәресләрдә балалар күңел үсү һәм кәеф китү, ярсу һәм өметсезлек, канәгатьлек хисе һәм кызыклы фикер яки әсәр героеның эшләнгән эшеннән күңел булу тойгыларын кичерергә тиеш.

Шуңа күрә укытучыларның да, ата-аналарның да балаларны карарга һәм күрергә, тыңларга һәм ишетергә — тирә-юньнән тәэсир һәм күзаллау тупларга өйрәтүе мөһим. Хисләр һәм фикер белән бергә сөйләм үсә, балалар тирән фикерле, көчле образлы әдәби әсәрләрне тормышның үзенчәлекле гәүдәләнеше итеп кабул итәргә өйрәнәләр.

Дәрестән тыш уку программада аерып күрсәтелми. Мөстәкыйль уку өчен биремнәр дәреслекләрдә өйрәнелгән әсәргә бәйле рәвештә куелырга тиеш. Алар сыйныфта укылганны тулыландыра, укучыны үзе теләп китап укырга һәм төрле чыганаклардан мәгълүматлар табарга өйрәтә.

**Кычкырып, аңлап, дөрес һәм сәнгатьле уку тизлеге (1 минутка)**

| сыйныфлар | I ярты ел | Уку елы ахырында |
|---|---|---|
| I | — | 30 сүз |
| II | 40 сүз | 50 сүз |
| III | 60 сүз | 75 сүз |
| IV | 85 сүз | 95 сүз |

***Стандартка туры килгән программа һәм дәреслек башлангыч сыйныф укучысының түбәндәге шәхси сыйфатларын күзалларга ярдәм итә:***

-укучы үз халкын, туган ягын һәм туган илен ярата;

-гаиләдәге һәм җәмгыятьтәге кыйммәтләрне хөрмәт итә, аларны кабул итә;тирә-якны актив рәвештә танып белергә омтыла;

-белем алу өчен кирәкле һәм файдалы булган эш формаларын үзләштерә;

-гаиләһәм җәмгыять алдындагы бурычларын аңлый, үзенең кылган гамәлләре өчен җавап бирергә сәләтле булуын күрсәтә;

-тирә-яктагыларга игътибарлы һәм ихтирамлы, аларны тыңлый һәм аларга үз фикерен яки мөнәсәбәтен белдерә ала;

-үзенеңһәм тирә-юньдәгеләрнең сәламәт яшәү рәвеше кагыйдәләрен үтәвенә булышлык итә.

***Программа һәм дәреслек укучыларның беренче сыйныфта алган белемнәренә түбәндәге таләпләрне куя:***

-шәхес буларак, укучы белемен үстерергә әзер, укуга һәм тирә-якны танып белүгә сәләтле, гражданлык позициясен күрсәтердәй шәхси сыйфатларга ия;

-үзе өйрәнгән предмет – татар теленнән яңа белем һәм күнекмәләр алып, дөньяны фәнни яктан күзаллый белә торган шәхес;

- үз иле һәм халкы өчен горурлык хисләренә ия булган укучы;

-төрле халыкларга, аларның тарихына һәм мәдәниятенә карата хөрмәт һәм ихтирам хисләренә ия;

-бик тиз үзгәрүчән тирәлеккә яраклаша белүгә сәләтле;

-рухи-әхлакый сыйфатларга ия булган хәлдә, укучы үзенеңһәм иптәшләренең бәхәсле хәлләрдән чыга белү күнекмәләренә ия булуын күрсәтергә сәләтле;

-тыныч һәм сәламәт яшәү рәвешенә йөз тотып, укучыда иҗади эш белән кызыксына, матди һәм рухи кыйммәтләргә сакчыл
карый белә.

**Программа буенча каралган материалны үзләштерү нәтиҗәсендә, укучылар түбәндәгеләрне өйрәнә:**

- Россия Федерациясендәге телләрнең һәм мәдәниятларның күп төрле булуы турында башлангыч мәгълүмат ала;

-телнең милли мәдәни күренеш һәм аралашу чарасы булуына төшенә, рус теленең Россия Федерациясендә дәүләт теле буларак тоткан урынын һәм аның төрле милләтләр арасында аралашу коралы булуын аңлый;

-укучыларда телдән һәм язма сөйләмне дөрес итеп төзүгә уңай караш тәрбияләнә, алар аны

шәхеснең тәрбияле булу билгесе итеп кабул итә;

-туган телдә (татар телендә) башлангыч орфоэпик, лексик һәм грамматик төшенчәләрне, сөйләм әдәбе кагыйдәләрен үзләштерә, аралашуның максат һәм бурычларыннан чыгып, тиешле тел берәмлекләреннән урынлы итеп файдалана белә;

-аралашу вакытында өйрәнелгән тел берәмлекләрен танып-белә һәм гамәли максатлардан чыгып файдалана.

***Телне система буларак өйрәнү.***

***“Фонетика. Графика”*** бүлегендә укучылар түбәндәгеләрне үзләштерә:

- аваз һәм хәрефләрне аерырга өйрәнә;
- татар телендәге сузык һәм тартык авазларга характеристика бирә: сузык авазларның калын һәм нечкә булуы, тартык авазларныңяңгырау һәм саңгырау төрләргә бүленүе күрсәтелә;
- татар алфавитын, андагы хәрефләрнең урнашу тәртибен белә, сүзләрне алфавит тәртибендә урнаштыру һәм кирәкле мәгълүматны эзләүөчен алфавиттан файдаланырга өйрәнә.

***“Орфоэпия”*** бүлегендә түбәндәгеләрне үзләштерү мөмкинлеге бирелә:

- дәреслектә бирелгән материал күләмендә укучы үзенеңһәм әңгәмәдәшенең сөйләмендә татар әдәби теле нормаларының саклануын аңлый;
- сүзне дөрес әйтү-әйтмәве яки сүз басымын дөрес кую-куймавы хакында икеләнгән очракта, укучы үз җавабының дөреслеген дәреслектәге сүзлекчәдән карап яки укытучыдан мөстәкыйль рәвештә сорап белә ала.

***“Лексика”*** бүлегендә укучылар түбәндәгеләрне үзләштерә:

- мәгънәсе ачыкланырга тиешле сүзләрне таба белә;
- тексттагы (җөмләдәге) сүзнең мәгънәсен ачыклый белә яки аны аңлатмалы сүзлек ярдәмендә аера.

***“Сөйләм үстерү”*** бүлегендә укучы:

- иҗекләрдән сүзләр, сүзләрдән сүзтезмәләр һәм җөмләләр төзеп әйтә. Терәк сүзләр ярдәмендә җөмләләр төзи;
- аерым темалардагы сүзләрне кертеп, тәкъдим ителгән грамматик конструкцияләр нигезендә, җөмләләр төзи, сорауларга җаваплар бирә, 3-4 җөмләдән торган бәйләнешле сөйләм оештыра;
- рәсемнәргә сораулар куярга,сорауларга җавап кайтара, рәсембуенча кечкенә хикәяләр төзергә өйрәнә;
- шигырь, мәкаль, әйтем һәм табышмаклар ятлый;
- татар сөйләм этикетына хас булган сүзләрне дөрес кулланып сөйләм оештыра (танышканда, саубуллашканда, табын артында утырганда, рәхмәт әйткәндә, мөрәҗәгать иткәндә, гафу үтенгәндә, тәбрикләгәндә һ.б. очракларда).

**1 класс**

**Курс 33 сәгатькә исәпләнгән (атнага 1 сәгать исәбеннән)**

Программа яңа укыту стандартлары таләпләрен искә алып, үстерешле укыту принциплары белән традицион белем бирү принципларының үзара тыгыз бәйләнештә булуын тәэмин итә торган «Перспектив башлангыч мәктәп» концепциясенә нигезләнеп эшләнде.

Программаның тәэмин ителеше:

- И. Х. Мияссарова, Ф. Ш. Гарифуллина, Р. Р. Шәмсетдинова, “Әлифба”. 1 сыйныф. Дәреслек.. — К, Мәгариф/Вакыт 2015.

Сафиуллина Г. М. һ.б. Әдәби уку 1 сыйныф. Дәреслек.. — К, Мәгариф/Вакыт 2011.
***<u>Әзерлек чоры (3 сәгать)</u>***

Әкият текстын тыңлау. Иллюстрацияләрнең (рәсемнәрнең) текст өлешләре белән бәйләнешен (мөнәсәбәтен) ачыклау. Әкият эчтәлеген сөйләү.

Балаларда текст турында, беренчедән, мәгънә ягыннан үзара бәйләнгән һәм хәбәр итү

интонациясе белән әйтелә торган, якынча тәмамланган фикерне белдерүче, билгеле бер эзлеклелектә килгән сүз һәм җөмләләр җыелмасы буларак, икенчедән, нәрсә турында да булса хәбәр итүче һәм ишетеп, күреп зиһенгә алына торган мәгълүмат буларак башлангыч күзаллау булдыру. Иллюстрация темасы буенча җөмләләр төзү. Конкрет җөмләләр белән текстның график моделе арасындагы мөнәсәбәтне ачыклау. Рәсем белән бирелгән хикәяне исемләү (исем кушу). Текст төзү элементлары. Тәкъдим ителгән график моделе буенча хикәя эчтәлеген сөйләү.

Укылган текст эчтәлеге буенча бирелгән укытучы сорауларына җавап бирү. Текст эчтәлеген сайлап алып сөйләү, шигырь ятлау. Телнең структур берәмлеге буларак сүз турында башлангыч күзаллау булдыру. Басма хәрефләрнең элемент-өлгеләре белән танышу. **Әзерлек чоры ахырына балалар**:

1. Элементар образлы күзаллау дәрәҗәсендә тел берәмлекләре: сүз, җөмлә, текстны **аңлый**, шулай ук татар алфавитының басма һәм язма хәрефләр системасын **атый һәм формалары буенча аера белергә**;.

2. Рәсем, график модель яки тиешле фишкалар кулланып, беренчедән, дәрестә тудырылган тел ситуацияләре буенча 2 — 4 сүздән торган **җөмләләр** һәм 3

— 4 җөмләдән торган **хикәя төзи**; икенчедән, парта артында **дөрес утыра** һәм язма әсбаплардан дөрес **файдалана**, алгоритм буенча яки тактлап язма хәрефләрнең барлык элементларын да **дөрес яза белергә тиешләр.**

***<u>Әлифба чоры ( 19сәгать)</u>***

**Сузык авазлар (3 сәг)**

Сузык **[а, ә, ы, э, и, у, ү, о, ө]** авазларының сүздә төрле позициядә килгән һәм аерым кулланылган очрактагы артикуляцияләрен ныгыту. Сузык авазларны аеру күнегүләре. Иҗек ясау процессында сузыкларның роле. Сүз кисәге буларак иҗек турында белешмә. График схема буенча сузык авазны әйткәндә, сузыкка басым куеп әйтү. Сүзнең график схемалары буенча сүзне көйләп,иҗекләргә бүлеп салмак һәм орфоэпик дөрес уку. Сүзнең иҗекләргә бүленешен дуга ярдәмендә билгеләү.

Схемада сузык авазны башта түгәрәк, соңыннан транскрипция билгесе белән билгеләү. Ишетелгән һәм әйтелгән сүзләр арасыннан өйрәнелә торган аваз кергән сүзне таный һәм аера белергә өйрәнү. Өйрәнелгән сузык аваз кергән сүзләр сайлау.

Элемент-өлге ярдәме белән басма хәрефләр төзү һәм аларның формаларын үзләштерү. Хәреф турында авазның тышкы билгесе, ягъни «киеме» буларак образлы күзаллау булдыру.

Укытучы укыган текстны тыңлау, эчтәлеген аңлау, куелган сорауларга җавап табу, ишетеп кабул ителгән текстның эчтәлеген тулысынча яки сайлап сөйләү.

**Парсыз сонор тартык авазлар (3 сәг)**

**[м, н, л, р, й, ң]** сонор тартык авазлары. Бирелгән авазларның артикуляциясе : үпкәдән килә торган һава агымы бер сөйләм органында, мәсәлән иреннәрдә, тешләрдә, тел алдында, тел уртасында, тел артында киртәгә яки тоткарлыкка очрый, бу авазларны әйткәндә тон өстенлек итә, шау катнаша гына. Шуңа күрә ул авазларны ярым сузыклар дип тә йөртәләр. Калын һәм нечкә яңгырашлы сүзләрдә сонор тартык авазлар әйтелешен чагыштыру; язуда аларның калын яңгырашын калын сузык аваз хәрефләре **(а, у, о, ы)** белән **(ма, му)**, нечкә яңгырашын нечкә сузык аваз хәрефләре **(ә, и, ө, ү, э)** белән белдерү.

Сүздә һәр авазны аерып әйтү алымы. Рәсем һәм схема белән бирелгән сүзләргә аваз анализы. Анализлана торган сүз составына кергән аерым аваз артикуляциясе. Тартык авазларның яңгыраулыгын белдерүче билге — уртасында нокта булган квадрат белән билгеләү. Чагыштыру өчен бирелгән сүзләрдәге **(мал-мәл)** авазларның аермалы билгеләренең мәгънә функциясенә ия булуын билгеләү. Сонор авазларны белдерүче басма баш һәм юл хәрефләрнең формаларын үзләштерү. Ябык иҗекләрне **(ай)** һәм калын һәм нечкә яңгырашлы кушылмаларны**(ма, мә, му, мү һ.б.),** шулай ук парсыз тартык авазлар уртада һәм ахырда булган сүзләрне **(май, малай)** уку. Сүзләрне иҗекләп уку белән чагыштырып, орфоэпик уку һәм әйтү алымы.

**Сүз башында һәм сүз уртасында |й| авазы (3 сәг)**

**Я, е, ю** хәрефләренең ике авазга **[йа]**, **[йә]**, **[йы]**, **[йә]**, **[йу]**, **[йү]** билге булып килүләре: **яра, ял, юл, куян, баян.** Аваз-хәреф схемаларын иҗекләп һәм орфоэпик дөрес итеп уку. Шартлы билгеләр һәм басма хәрефләр нигезендә сүзнең аваз формасын график формага күчерү процессын күзәтү. **Я, е, ю** хәрефләрен куллану кагыйдәләрен үзләштерү. Бу хәрефләр кергән сүзләрне һәм иҗекләрне уку. Баш һәм юл басма хәреф формаларын төзү.

**Яңгырау һәм саңгырау парлары булган тартыклар (7 сәг)**

Яңгырау һәм саңгырау тартыкларны калын һәм нечкә яңгырашын билгеләү: нечкәлек

яңгырау, саңгырау (**[д-т],[з-с],[г-к],[гъ-къ]** һ.б.) парларның үзара мөнәсәбәтен ачыклау. Мәсәлән **бар-бар, бар-пар** һ.б. Өйрәнү тәртибендә басма хәреф формаларын үзләштерү. Авазларында аерма булган сүзләрне, яңгырау һәм саңгырау тартык авазлардан башланган сүзләрне әйтеп карау, чагыштыру күнегүләре **(бар-пар).**

Аваз-хәреф схемалары нигезендә авазларны аеру, иҗекләр, сүзләр, текстлар уку. Башлангыч сүзне һәм **сүзнең авазын алмаштыру** яки **аваз өстәү юлы** белән ясалган яңа сүзләрне **(бур-бура-буран)**, шулай ук ике яктан да бертөрле укыла торган **(ана)** сүзләрне уку. Табышмаклар уку һәм аларның җавабын табу. Тизәйткечләр, санамышлар, үртәвечләр, өйрәнелә торган аваз булган халык мәкальләрен уку, истә калдыру һәм хәтер буенча сөйләү. Аваз. иҗек.сүз.җөмлә һәм текст турында образлы күзаллау формалаштыру

**Парсыз тартык авазлар (2 сәг)**

Парсыз **[х, һ, щ, ц]** тартыклар артикуляциясе. Бу авазларның характеристикасы. Парсыз тартык авазлар кергән иҗекләр һәм сүзләр, текстлар уку. Текстның эчтәлеген үзләштерү. Эчтәлеген сөйләү. Басма хәрефләрнең формаларын үзләштерү.

**Аеру билгеләре булып торган ь һәм ъ тан соң [й] авазы (1 сәг)**

Язуда аеру билгеләре булып торган **ь** һәм **ъ** һәм сузык аваз хәрефләре ярдәмендә **[й]** авазының язуда бирелешен **(ь+е, я, ю; ъ+е, ю, я)** аңлату. (**Я, е, ю**

хәрефләре алдындагы иҗек калын сүзләргә **(альяпкыч) ъ** билгесе, **алдагы** иҗек нечкә сүзләргә **(дөнья)ь** билгесе куелуын аңлатыла).

Аеру билгеләре һәм сузык аваз хәрефләре белән белдерелгән **[й]** авазлы сүзләрнең аваз анализы. **[Й]** авазы кергән сүзләрнең аваз схемасын уку. аны хәреф формасына үзгәртү, соңыннан башта иҗекләп, аннан соң орфоэпик дөрес итеп уку. **Ь, ъ** билгеләренең басма хәрефләрен төзү һәм аларның формаларын үзләштерү. (Бу билгеләрнең [гъ], [къ] авазларының калынлыгын белдерү өчен дә кулланылуын аңлату **(игътибар, тәкъдим).**Калын **[гъ]** һәм **[къ]** авазлары булган сүзләрнең калынлыгын белдерү өчен язуда калын сузык аваз хәрефләре куланылуын, әйткәндә, иҗек нечкәлеген белдерү өчен, ахырдан **ь** билгесе куелуын ассызыклан үтәргә кирәк. Мәсәлән **мәкаль** сүзендә **[къ]** калын кече тел тартыгы, аның калынлыгын белдерү өчен **к** дан соң **а** язабыз, укыганда**[мәкъәл]**дип укыйбыз, икенче иҗекне нечкә итеп уку өчен сүз ахырына **ь** билгесе куябыз.) **Ь, ъ** билгеләренең басма хәрефләрен төзү һәм аларның формаларын үзләштерү.

**Шәхескә юнәлтелгән УУГ (универсаль уку гамәлләре)**

- кече яшьтәге мәктәп баласы үзе тел берәмлекләрен танып, таныш һәм таныш булмаганнарга бүлә белү;
- биремнәр системасында ориентлашырга өйрәнү. Этик-әхлак ориентациясе
- эти-әни һәм бала арасындагы мөнәсәбәт, бер-береңне ярату, хөрмәт итүгә багышланган текстларны таба, кирәкле урынын аера белү;
- “Минем өчен уку нинди мәгънәгә ия?”соравына җавап бирә белү;
- дәрестә үзенең белем һәм күнекмәләрен куллану;
- иҗади эшчәнлеккә омтылыш булдыру;
- үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру;
- үз фикереңне әйтә белү.

**Танып белү универсаль уку гамәлләре**

Информация бирүче:

- үзенә кирәкле информацияне таба белү; анализлый һәм информацияне бәяли белү. Логик:

Объектларга хас билгеләрне таба :

- авазларны аеру өчен модельләрне чагыштыру, яңа хәреф билгеләнешен өйрәнү;
- яңгырау һәм саңгырау авазларны анализлый, алар арасындагы охшаш яки аермалы якларны табу;
- парлы яңгырау һәм саңгырау авазларны анализлый, алар арасындагы охшаш яки аермалы якларны (тавыш, яңгыраш) таба, яңгырау һәм саңгырау авазларның чиратлашуын аңлату;
- я, ё, ю,е хәрефләренең үзенчәлеген белә, ь, ъ тан соң укылышына игътибар итү;
- ь, ъ хәрефләренең кулланылышын аңлату;
- парсыз тартыкларны табу.

Объектларны таный, аларга гына хас билгеләрне күрсәтә:

- “аваз”төшенчәсе формалаштыру, модельдә күрсәтү:
- “ парлы яңгырау-саңгырау “тартыклар төшенчәсе формалаштыру, капма каршы кую;
- төсле фонда бирелгән сүзләрне чагыштырып, авазларның ролен ачыклау;
- “хәреф –аваз билгесе” төшенчәсе булдыру, сүзләрнең схема-модельләрен карау.
- ялгызлык исемнәрендә баш хәреф; җөмләдәге сүзләр арасындагы бәйләнешне ачыклау; сүзләрдән җөмләләр, ә җөмләләрдән аңлаешлы текст төзү.

**Регулятив (көйләгеч) универсаль уку гамәлләре**

- көч һәм энергия туплау, конфликтларны һәм каршылыкларны чишү максатында ихтыяр көчен үстерү;
- белгәнне һәм белмәгәнне аера белү;
- үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, рәсемнәр ярдәмендә биремне үтәүнең дөреслеген тикшерү;
- эшләнәчәк эшкә мөстәкыйль максат куя белү;
- үз-үзеңне ихтыяр буенча көйләү;
- бәяләү нәтиҗәсен шартлы символик формада чагылдыру;
- дәрестә өйрәнелгән материалның фәнне өйрәнүдәге, тормыштагы әһәмиятен ачыклау;
- тормыш тәҗрибәсен куллану;
- үтәлгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү, уңышлылыгына бәя бирү;
- укучылар тарафыннан белгән яки әлегәчә белмәгән күнекмәләрне үзара бәйләү.

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре**

- тыңлаучыларга аңлаешлы сөйләм төзү;
- күзаллау, фаразлау;
- логик фикер йөртү осталыгы;
- күршең белән хезмәттәшлек итү;
- фикерләү сәләтен үстерү, карарлар кабул итү һәм аны тормышка ашыру;
- үз фикереңне тулы, төгәл һәм ачык, аңлаешлы итеп әйтү, аны яклау;
- җитмәгән мәгълүматны башкалардан сорашып белү;
- иптәшеңнең үз-үзен тотышы белән идарә итү. **Әдәби уку 1 нче бүлек. Аңлатма язуы** Программаның тәэмин ителеше:

Сафиуллина Г. М. һ.б. Әдәби уку 1 сыйныф. Уку әсбабы. — К, Мәгариф/Вакыт 2015

Сафиуллина Г.М. һ.б.. Әдәби уку 1 сыйныф Мөстәкыйль эшләр дәфтәре. — . К, Мәгариф/Вакыт 2015.

Сафиуллина Г.М. һ.б. Укытучылар өчен методик кулланма «Әдәби уку» 1сыйныф, — К, Мәгариф/Вакыт 2015.

**Әдәби уку** — башлангыч мәктәптә төп предметларның берсе. Бу фән аша кече яшьтәге мәктәп баласына һәрьяклы белем бирелә. Укучының аңы дөньяны: әдәби әсәрләрне генә түгел, безне чолгап алган тирәлекне — кешеләр һәм табигать дөньясын да — дөрес кузалларлык сизгер була. Бары тик югары аң тәрбияләп кенә әйләнә-тирәлекне дөрес күзалларга мөмкин. Федераль дәүләт белем стандарты информацион җәмгыятьтә аралашырлык шәхеснең күпьяклы үсешен күздә тота. Башлангыч мәктәптә әдәбият дәресләренең төп максаты: 4 ел уку дәверендә балада дөрес һәм йөгерек уку күнекмәләре булдыру, халык авыз иҗаты, язучы һәм шагыйрьләр әсәрләре белән якыннан таныштыру, чәчмә һәм шигъри әсәрләрне укып, эстетик ләззәт алырга өйрәтү. Төп идеяләр берничә һәм бу идеяләрне тормышка ашырмыйча торып максатка ирешергә мөмкин түгел. Федераль дәүләт белем стандарты информацион җәмгыятьтә аралашырлык шәхеснең күпьяклы үсешен күздә тота.

**Беренче идея.** Уйдырмалар (мифлар), халык авыз иҗаты белән авторлар әсәрләренең бәйләнеше турында дөрес кузаллау булдырырга кирәк. Халык авыз иҗаты белән танышу язучылар әсәрләре белән таныштыруның алшарты булып тора. Аларны өйрәнү автор әсәрләрен уку белән параллель алып барыла. Язучылар үз әсәрләрендә түбәндәгеләрне куллана:

1) халык авыз иҗатының жанр төзелеше (әкият жанры);
2) халык авыз иҗаты әсәрләренең сюжет-композиция төзелеше;
3) кабатлаулар һәм әдәби иҗат алымнары.

Автор әсәрләрендә халык авыз иҗатын куллану гына әсәрне фольклор әсәрләр рәтенә кертми әле. Биредә конкрет кешенең уй һәм кичерешләре табигать ритмнарына туры китереп бирелә. Язучылар әсәрләре, тарихи вакыйгаларны үз эченә алып, кешеләрнең кичерешләре белән үрелеп барыла. Ә фольклор әсәрләрендә тылсымлы дөньяда яшәү күрсәтелә һәм ул һәрвакытта да геройларның җиңүе белән тәмамлана.

**Икенче идея.** Әдәбият дәресләрендә, ашыкмыйча гына, әдәби образ төшенчәсен кертә бару сорала (әдәби образ термины, билгеле, кулланылмый) Кече яшьтәге мәктәп баласын үзе аңларлык әдәби алымнар: чагыштыру, капма-каршы кую һ.б. таныштырып бару кирәк була. Сәнгать әсәрләре, графика аша укучыларга әдәби образларның сынлы сәнгатьтәге ролен аңлатырга ярдәм итә.

**Өченче идея.** Кече яшьтәге мәктәп баласын башта халык авыз иҗаты әсәрләре жанрларын, ә соңыннан әдәби жанрларның үзләрен дә аера белергә өйрәтергә кирәк. Шулай ук һәр жанрның шартлы чикләрен билгеләргә өйрәтү дә таләп ителә.

**Дүртенче идея**. Кече яшьтәге мәктәп баласын шигъри әсәрләрне яратырга һәм аларны укып ләззәтләнә белергә өйрәтергә кирәк. Ә башлангыч сыйныфларда боларны өйрәтә алмасак, сәнгатьнең бер төре буларак поэзия алга таба күп кенә укучылар өчен аңлаешсыз булып калачак. Махсус терминнар кертмичә генә, укучы аңында поэзиянең үзенчәлекләрен аңлату зарур. Рифма турында (парлы яки янәшә (аа,бб, вв,...), аралаш яки юл аша ( аб, ав), әйләнмә яки камаулы-боҗралы (абба,абва) формаларда була дип, шулай ук шигырь үлчәме турында да кузаллау булдырыла.

Әдәби уку курсында һәр уку елының үзенең аерым үзенчәлекләре бар. Бу фәнне укытуның төгәл бурычлары программа таләпләрендә ачык чагыла.

**2 нче бүлек : 1нче сыйныф өчен программа таләпләре:**балада дөрес һәм йөгерек укуга ихтыяҗ булдыру (текстлар балаларга ошарга, тиз истә калырга, күбрәк уку теләге, уку барышындагы кыенлыкларны җиңү теләге уятырга тиеш);

- алты-җиде яшьтәге балада беренчел уку күнекмәләре булдыру (шигъри әсәрләр белән бала кечкенәдән — балалар бакчасында йөргәндә үк таныш була, шигырь юлларының кыскалыгы укуга теләк уята, рифма аңа сүзне табарга ярдәм итә, үз көченә ышаныч уята, ритм кечкенә балаларның яшәү рәвешенә туры килә);
- әдәбият үсешенең халык авыз иҗатыннан язма формаларга күчү эзлеклелеге аңлатыла (беренче сыйныф укучылары халык авыз иҗатының төрле формалары: фольклорның кече жанрлары, әйләнмәле, чылбыр, алдавыч әкиятләр, төрле авторларның балалар өчен язылган шигырьләре, кыска хикәяләр белән таныша );
- алты яшьлек баланың әхлакый һәм эстетик үсеш дәрәҗәсе иң алгы планда тора (халык авыз иҗаты һәм әдәби әсәрләрнең сюжеты уен характерында бара; күпчелек текстлар балаларда юмор хисе тәрбияләүгә юнәлтелә).

3 нче бүлек: **1 нче сыйныф программасы эчтәлеге.**

Балалар Әлифбадан әдәби укуга сиздермичә генә, эзлекле рәвештә күчәргә тиеш. Кече яшьтәге мәктәп балалары аңлап укуның беренчел күнекмәләрен ала, халык авыз иҗатының жанрлары белән таныша һәм аларны тормышта кулланырга өйрәнә. Аптыраткыч-алдавыч, әйләнмәле, чылбыр әкиятләрнең сюжет-композиция үзенчәлекләрен аера, авторларның чәчмә һәм шигъри текстлары белән таныша. Халык авыз иҗаты һәм шагыйрьләрнең шигъри әсәрләре аша, юл ахырындагы охшаш сүзләргә нигезләнеп, рифма, кабатлаулар, сәнгатьлелек турында беренчел кузаллау булдырыла. Кыска текстлар һәм аларга ясалган иллюстрацияләрне чагыштырып, әдәби образның сәнгатьнең төрле төрләрендә тасвирлануы аңлатыла.

Беренче сыйныфны тәмамлаганда бала текстны аңлап укырга һәм аның эчтәлеге буенча үз фикерләрен әйтә белергә тиеш (дәреслектә бирелгән конкрет сорауларга җавап бирү формасында). Балаларда халык авыз иҗаты турында гомуми күзаллау булдырыла, алар проза һәм поэзиянең үзенчәлекләрен танып беләләр, “автор”, “әсәрнең исеме” төшенчәләре бирелә, әсәрдәге персонажларны танып әйтә алалар. Беренче сыйныфтагы төп бурыч — укуга кызыксыну тәрбияләү һәм дөрес уку күнекмәләре булдыру — икенче сыйныф өчен дә актуаль булып кала. Кыска текстлар һәм аларга ясалган иллюстрацияләрне чагыштырып, әдәби образның сәнгатьнең төрле төрләрендә тасвирлануы аңлатыла.

**Программа** әдәби әсәрләр белән эшләү юллары, алымнары белән таныштыра, шул ук вакытта укытучыга иҗади эшләү мөмкинлеге дә калдыра.

Шигырь һәм проза. Шигъри һәм чәчмә әсәрләр турында гомуми кузаллау булдыру. Әдәби әсәрнең исеме, авторы (язучы, шагыйрь), халык авыз иҗатында билгесезлек (авторы юк).

**Халык авыз иҗаты һәм әдәбият**

Халык авыз иҗаты турында гомуми кузаллау булдыру. Авторның булмавы, телдән сөйләм, практик-уен характерындагы кече жанр әсәрләре. Бишек җырлары, санамыш, табышмак,

тизәйткеч, эндәшләр. Әйләнмәле һәм чылбыр әкиятләр. Халык авыз иҗатының табышмак, әйләнмәле әкият кебек формаларын практик яктан үзләштерү. Сурәтләнгән вакыйгаларга карата автор фикере (әсәр исеме, геройларга характеристика, авторлар бәяләмәсе).

**Әсәрнең эмоциональ тоны**

Юмористик һәм җитди характердагы әсәрләр. Әсәрләрне китаптан кычкырып, яттан укыганда эмоциональ характерны чагылдыра белү. Тавыш төсмерләре: интонация, тон, тавыш көче, тембр, темп, пауза, логик басым, сүзсез мимика, хәрәкәтләр, ымнарны дөрес бирә алу.

**Әдәби сәнгатьлелек чаралары**

Текстны анализлау барышында сәнгатьлелек чараларын табарга күнектерү. Сурәтләү чаралары турында беренчел кузаллау булдыру, кабатлауларның мәгънәсенә төшенү, тавышның сәнгатьлелеген ачыклау: рифма, ритм төшенчәсе бирү.

**Әдәби жанрлар**

Жанрлар турында гомуми кузаллау булдыру:

**Хикәя.** Хикәянең исеме. Ике образны чагыштырып сөйли белү. Әсәрдәге геройларга карата үз фикерен белдерү.

**Шигырь.** Дөньяны шагыйрьләр күзлегеннән чыгып танып белү: шагыйрь матурлыкны тоя белергә өйрәтә. Рифма белән танышу: аны таба, куллана белергә күнектерү.

**Яңа стандарт куйган таләпләр.**

Базар икътисадының бүгенге таләпләре һәм мәгълүмати җәмгыятьнең тиз темплар белән формалашуы мәгариф системасы алдына яшь буынга белем бирү максатын һәм бурычларын, форма һәм эчтәлеген тамырыннан үзгәртү мәсьәләсен куйды. Мәгариф системасындагы яңалыкларны гамәлгә ашыруда төп көч вазифасын үтәү өчен икенче буын дәүләт стандартлары төзелә.

Икенче буын стандартларының нигезен яңа төр мөнәсәбәтләр тәшкил итә: бүген укучының билгеле бер белем дәрәҗәсенә ия булуын дәүләт кенә түгел, ә бәлки укучы, аның әти-әнисе дә дәүләттән билгеле бер күләмдә сыйфатлы белем бирүен таләп итү хокукына ия.

Ә хәзер башлангыч мәктәп өчен төзелгән яңа стандартларның төп характеристикасы белән танышып узыйк. Икенче буын стандартлары шәхес үсешен тәэмин итү, укытуга үз эшеңне төптән белеп якын килү бурычын куя. Башкача әйткәндә, мәгариф системасы баланы белемле итү хакында гына түгел, аңа күнекмәләр бирү, аны эшкә өйрәтү турында да кайгырта.

Яңа стандартларның тагын бер ягын ассызыклап үтәргә кирәк: аларда укучыга һәм укытучыга гына түгел, ә бәлки барлык дәрәҗәдәге мәгариф системасына (федераль, төбәк, район мәгариф системасына, мәктәпкә) билгеле бер җитди таләпләр куела. Таләпләрнең өч төркеме билгеләнгән: 1) базис укыту планының төзелешенә һәм эчтәлегенә; 2) аны үзләштерү нәтиҗәләренә; 3) укыту программаларын гамәлгә ашыру шартларына таләпләр.

Төп укыту программаларын үзләштерү нәтиҗәләренә таләпләр — һәр укучының гыйлем туплауда ирешкән казанышларын шәхси бәяләү критерийлары ул. Шул нигездә укучының танып-белү, универсал белем туплау (операциональ) эшчәнлегеннән, мәгариф системасының барлык дәрәҗәләрендә (республика, төбәк, аерым мәгариф учреждениеләрендә) эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген интеграль бәяләүдән гыйбарәт.

Нәтиҗәләргә таләпләр — гомуми белем программаларының барлык төрләренең состав өлеше. Алар шәхси, эшчәнлекнең гомумиләштерелгән ысуллары (метапредмет) һәм фәнне өйрәнү нәтиҗәләрен үз эченә ала.

Метапредмет нәтиҗәләренә стандартларда универсал уку эшчәнлеге дип билгеләнгән гомумиләштерелгән эшчәнлек ысуллары кертелә. Алар, уку-укыту кысаларында гына куллану белән бергә, кеше эшчәнлегенең төрле өлкәләрендә танып-белү яки гамәли мәсьәләләрне хәл иткәндә файдаланылырга мөмкин.

Яңа стандартта укыту күнекмәләре ике зур блокка — универсал блокка һәм фән блогына бүленгән. Универсал уку эшчәнлеге термины педагогикада бүген кулланыла торган гомуми уку күнекмәләрен, гомуми танып-белү, фәнне өстәмә өйрәнү эшчәнлеген алыштыра. Яңа стандартларны төзүчеләр аларны дүрт блокка —шәхси, регулятив, танып-белү һәм коммуникатив блокка берләштергән.

**Шәхси эшчәнлек** баланың тормыш кыйммәтләрен, әхлакый һәм мораль нормаларны аңлавын һәм кабул итүен, аның әйләнә- тирәсендәге барлык нәрсәгә шәхси карашы формалашуны аңлауга юнәлтелгән.

**Регулятив эшчәнлек** танып-белү процессы белән идарә итәргә булыша. Алар гыйлем

туплау мәсьәләсен кабул итү күнекмәсен, билгеле бер эшчәнлекне оештыруны планлаштыру, тикшерү, үзгәрешләр кертүне, үтәлгән эшнең уңышлылыгына бәя бирүне үз эченә ала.

**Танып-белү эшчәнлеге** тиешле мәгълүматны эзләү һәм анализлауны, хәл итү ысулларын һәм алымнарын модельләштерүне һәм куллануны тәэмин итә.

**Коммуникатив эшчәнлек** хезмәттәшлекне оештыруга һәм гамәлгә ашыруга юнәлтелгән. Ул партнерны тыңлый һәм аңлый белүдән, мәгълүматны тулы һәм төгәл кабул итә һәм тапшыра, үзеңнең эш-хәрәкәтеңне партнер эш-хәрәкәте белән чагыштыра белүне үз эченә ала.

***Укучыларның уку елында алган белемен бәяләүгә түбәндәгеләр кирә:***

— билгеле бер уку фәне өлкәсендә функциональ грамоталылык параметрлары: фән буенча тупланган һәм универсал ысуллар нигезендә тупланган уку бурычларын хәл итүгә сәләтлелек; теге яки бу фән эчтәлеге буенча белемнәр; алга таба белем алу өчен кирәкле база төшенчәләренә, төрле рәвештә бирелгән мәгълүматны кабул итү һәм анализлау күнекмәсенә ия булу;

— өйрәнелә торган объект һәм күренешләрнең уку-укыту модельләре белән эшләргә сәләтлелек;

— тормышта очрый торган төрле типик проблемаларны хәл итү өчен туплаган белемнәрне куллану күнекмәсе алу;

— төрле социаль рольне үтәү, контроль һәм үзконтрольгә сәләтлелек.

***Бәяләү нормалары.***

Әдәби уку дәресләренең төп вазифасы- укучыларда дөрес, йөгерек, сәнгатьле итеп, текстның эчтәлеген аңлап уку күнекмәләре булдыру һәм үстерү, аларны китап белән эшләү алымнарына өйрәтү. 4 нче сыйныфта аерым сүзләр белән йөгерек, аңлап укуга караган осталык һәм күнекмәләре камилләшә, сәнгатьле уку күнекмәләре тәрбияләнә. Уку техникасы сыйныфтан сыйныфка камилләшә барырга тиеш.

Уку сәләтен бәяләгәндә, текстның эчтәлеген аңлап, тиешле тизлектә, авазларны һәм сүзләрне дөрес әйтеп, интонацияне саклап, башкалар ишетерлек һәм аңларлык итеп уку мөһим. Кычкырып укыганда, сүзләрнең дөрес әйтелешенә игътибар ителә. Аерым җөмләләрне һәм текстны тиешле пауза белән логик басымны саклап укырга кирәк.

Кычкырып уку белән бергә, баланың эчтән уку мөмкинлекләрен камилләштерү турында да онытмаска кирәк. Эчтән уку тизлеге дә гомуми таләпләргә туры килергә тиеш.

Укуны гадел бәяләү максатыннан, укучыга 2-3 минутлык тоташ текст тәкъдим ителә. Шуннан соң аның уртача күрсәткечен ( 1 минутка ничә сүз укуын) табарга мөмкин.

**Уку күнекмәләрен бәяләү**

1. Программада каралган таләпләрне тулысынча үтәсә ( авазларны, сүзләрне, җөмләләрне дөрес, сәнгатьле итеп, пауза һәм логик басымны саклап укыса ); укытучы биргән сорауларга җавап кайтара алса яки текст эчтәлеген аңлы рәвештә үзләштерсә, **“5”** ле куела.
2. Уку тизлеге гомуми таләпләргә туры килсә; сәнгатьлелек сакланса, ләкин укыган вакытта 2-3 әйтелеш хатасы җибәрсә; пауза һәм интонациягә караган төгәлсезлекләр булса; текстның эчтәлеген аңлап, укытучы биргән сорауларга җавап кайтара алса, **“4”** ле куела.
3. Уку тизлеге гомуми таләпләргә туры килмәсә; текстны сәнгатьле итеп укымаса; логик басым дөрес куймаса; әйтелешкә караган 3-4 хата җибәрсә; текстны өзеп-өзеп укыса; укытучы биргән сорауларга җавап кайтарганда, төгәлсезлекләр китсә; 4-5 әйтелеш хатасы җибәрсә, **“3”** ле куела.
4. Уку тизлеге бик акрын укымаса; әйтелеш нормаларын тупас бозса; орфоэпия һәм интонация хаталары эчтәлекне аңлауга җитди комачаулык тудырса; сүзләрне әйткәндә, 6 дан артык тупас бозып әйтү булса, **“2”** ле куела.

**Укучының монологик сөйләмен бәяләү**

Бирелгән тема ( рәсем яки ситуация ) буенча хикәя төзи белсә; дөрес интонация белән, тулы, эзлекле, текст эчтәлегенә үз мөнәсәбәтен, бәясен биреп сөйли алса, тупас булмаган пауза хаталары булса да, **“5”** ле куела.

4 нче сыйныфта бәйләнешле сөйләм 10-12 җөмлә тәшкил итә.

Аерым паузалар, 1-2 сөйләм хатасы ясаса, укытучы тарафыннан 1-2 ачыклаучы сорау бирелсә, **“4”** ле куела.

Теманың төп эчтәлеген ачса, 4-6 сөйләм хатасы ясаса, укытучы тарафыннан икедән артык ачыклаучы сорау бирелсә яки укытучы ярдәменнән башка сөйләмне башлый алмаса **“3”** ле куела.

Сөйләмдә эзлеклелек сакланмаса, паузалада төгәлсезлекләр китсә, 6 дан артык сөйләм хатасы һәм грамматик хата ясаса, “2” ле куела.

**Диалогик сөйләмне бәяләү**

Тиешле темпта дөрес интонаөия белән сорау куйса, әңгәмәдәшенең сорауларына тулы җавап кайтарса, **“5”** ле куела.

Дөрес сорау биреп, үзе дә әңгәмәдәшенең соравына дөрес җавап кайтарса, ләкин сөйләм вакытында укытучы ярдәменә мохтаҗ булса, 2-3 сөйләм хатасы җибәрсә, **“4”** ле куела.

Укытучы ярдәмендә генә сорау бирсә яки җавап кайтарса, сораулар биргәндә, сүзләр һәм грамматик формалар табуда төгәлсезлекләр җибәрсә яки өйрәнгән җөмлә калыпларының бер өлешен генә үзләштерсә, 4-5 3 сөйләм хатасы җибәрсә, **“3”** ле куела.

Әңгәмә вакытында зур авырлык белән генә сорау бирсә, сорауларга үз көче белән җавап бирә алмаса, 6 дан да артык хата җибәрсә, **“2”** ле куела

“Әдәби уку” курсыннан эш программасы 2 өлештән тора:

5. булса; барлык сүзләрне дә өзеп-өзеп укыса; текстны сәнгатьле, аңлаешлы итеп

| **I. ГРАМОТАГА ӨЙРӘТҮ ПРОГРАММАСЫ** | **II. ӘДӘБИ УКУ ПРОГРАММАСЫ** |
|---|---|
| Грамотага өйрәтү дәресләре (уку) атнага 1 сәгать исәбеннән төзелде.<br>**Барысы 23 сәгать.** | Әдәби уку дәресләре программасы атнага 1 сәгать исәбеннән<br>төзелде. **Барысы 10 сәгать**. |
| **Грамотага өйрәтү дәресләренең максаты:**<br>Укучыларны татар теленең график системасы төзелеше һәм функциясенең гомуми закончалыклары белән танышу нигезендә<br>башлангыч уку һәм язуга өйрәтү. Бу үз чиратында укучыларда тел турында белем һәм күнекмәләрнең формалашуына нигез булып тора. Грамотага өйрәнү чорында график эшчәнлекне үзләштерү — I сыйныф укучысының төп бурычы. Чөнки бу эшчәнлек нәтиҗәсендә балаларда уку һәм язу күнекмәләре формалаша.<br>Грамотага өйрәнү процессында балаларда татар теле системасының төп тел берәмлекләре (аваз, сүз, сүзтезмә, җөмлә, текст) турында күзаллау туа, фонематик ишетү һәм авазны әйтү культурасы үсә.<br>Алар, беренчедән, төрле шартлы модельләр (квадрат, түгәрәк) һәм махсус транскрипция билгеләре системасы нигезендә сүзнең аваз формасын күз алдына китереп әйтә алу; икенчедән, сөйләмнең<br>фонетик язуын тиешле басма яки язма хәрефләргә күчерү; өченчедән, сүзнең хәреф моделе буенча аваз формасын төзү эшчәнлеген, ягъни уку күнекмәләрен үзләштерәләр. Шул ук вакытта укучылар язма<br>хәрефләрне, аларны иҗекләргә, сүзләргә тоташтырып язу технологиясен дә үзләштерәләр. | **Әдәби уку дәресләренең максаты:**<br>• балада дөрес һәм йөгерек укуга ихтыяҗ булдыру (текстлар балаларга ошарга, тиз истә калырга, күбрәк уку теләге, уку барышындагы кыенлыкларны җиңү теләге уятырга тиеш);<br>• алты-җиде яшьтәге балада беренчел уку күнекмәләре булдыру (шигъри әсәрләр белән бала кечкенәдән — балалар бакчасында йөргәндә үк таныш була, шигырь юлларының кыскалыгы укуга теләк уята, рифма аңа сүзне табарга ярдәм итә, үз көченә ышаныч уята, ритм кечкенә балаларның яшәү рәвешенә туры килә);<br>• әдәбият үсешенең халык авыз иҗатыннан язма формаларга күчү эзлеклелеге аңлатыла (беренче сыйныф укучылары халык авыз иҗатының төрле формалары: фольклорның кече жанрлары, әйләнмәле, чылбыр, алдавыч әкиятләр, төрле авторларның балалар өчен язылган шигырьләре, кыска хикәяләр белән таныша );<br>• алты яшьлек баланың әхлакый һәм эстетик үсеш дәрәҗәсе иң алгы планда тора (халык авыз иҗаты һәм әдәби әсәрләрнең сюжеты уен характерында бара; күпчелек текстлар балаларда<br>юмор хисе тәрбияләүгә юнәлтелә). |
| **ТЕМАТИК ПЛАНЛАШТЫРУ** | |

| | |
|---|---|
| **Әзерлек чоры.  Уку (3 сәг.)**<br>Әкият текстын тыңлау, эчтәлеген сөйләү.<br>Балаларда текст турында башлангыч күзаллау булдыру. Рәсем белән бирелгән хикәяне исемләү .Текст төзү элементлары. Укылган текст эчтәлеге буенча бирелгән укытучы сорауларына җавап бирү. Текст<br>эчтәлеген сайлап алып сөйләү, шигырь ятлау. Сүз турында<br>башлангыч күзаллау булдыру. Басма хәрефләрнең элемент-өлгеләре белән танышу.<br>**Әлифба чоры  Уку (20 сәг.)**<br>Сузык авазларының артикуляцияләрен ныгыту. Сузык авазларны аеру күнегүләре. Иҗек турында белешмә. Элемент-өлге ярдәме белән басма хәрефләр төзү һәм аларның формаларын үзләштерү. Укытучы укыган текстны тыңлау, эчтәлеген аңлау, куелган сорауларга җавап<br>табу, ишетеп кабул ителгән текстның эчтәлеген тулысынча яки сайлап сөйләү.<br>Рәсем һәм схема белән бирелгән сүзләргә аваз анализы.<br>Аваз-хәреф схемаларын иҗекләп һәм орфоэпик дөрес итеп уку.<br>Шартлы билгеләр һәм басма хәрефләр нигезендә сүзнең аваз<br>формасын график формага күчерү процессын күзәтү. Яңгырау һәм саңгырау тартыкларны калын һәм нечкә яңгырашын билгеләү. Аваз-хәреф схемалары нигезендә авазларны аеру, иҗекләр, сүзләр, текстлар уку.<br>Табышмаклар уку һәм аларның җавабын табу. Тизәйткечләр, санамышлар, үртәвечләр, өйрәнелә торган аваз булган халык мәкальләрен уку, истә калдыру һәм хәтер буенча сөйләү.<br>Аваз. иҗек.сүз.җөмлә һәм текст турында образлы күзаллау<br>формалаштыру. Текстта сурәтләнгән вакыйгаларга укучы баланың һәм авторның мөнәсәбәтен белдерә белү. | ***Халык авыз иҗаты һәм әдәбият (5 сәг.).***<br>Балаларда халык авыз иҗаты турында гомуми күзаллау булдырыла. Авторларның булмавы, телдән сөйләм, практик-уен характерындагы кече жанр әсәрләре. Санамыш, табышмак, тизәйткеч, эндәшләр.Халык авыз иҗатының табышмак, әйләнмәле әкият кебек формаларын практик үзләштерү.<br>***Әдәби жанрлар (5 сәг.)***<br>Жанрлар турындагомуми күзаллау булдыру.<br>Рифма белән танышу: аны таба, куллана белергә күнектерү.<br>Кыска текстлар һәм аларга ясалган иллюстрацияләрне чагыштырып, әдәби образның сәнгатьнең төрле төрләрендә тасвирлануы аңлату.<br>Балалар проза һәм поэзиянең үзенчәлекләрен танып беләләр, “автор”, “әсәрнең исеме” төшенчәләре бирелә, әсәрдәге<br>персонажларны танып әйтә алалар. |

**1 КЛАСС**

| № п/п | Наименование разделов и тем программы | Количество часов | | | Электронные (цифровые) образовательные ресурсы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | всего | контрольные работы | Практические работы | |
| Раздел 1. **Обучение грамоте** | | | | | |
| 1.1. | Развитие речи | 1 | 0 | 0 | мультимедийные приложения к урокам татарского языка |
| 1.2. | Слово и предложение | 2 | 0 | 0 | мультимедийные приложения к урокам татарского языка |
| 1.3. | Чтение | 18 | 0 | 0 | мультимедийные приложения к урокам татарского языка |
| Итого по разделу | | 21 | | | |
| Раздел 2. **Систематический курс** | | | | | |
